ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 13 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 3 пунктына “, шулай ук аквакультура (балыкчылык) максатлары өчен” сүзләрен өстәргә;

2) $33^1$ статьяның 1 пунктындагы өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 40 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:
“$2^1$. Ясалма сугарыла торган авыл хуҗалыгы җирләре һәм (яисә) киптерелә торган җирләр өчен җир кишәрлегенең минималь күләме Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең агросәнәгать комплексы белән идарә итү өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.”;

4) түбәндәге эчтәлекле $40^1$ статья өстәргә:
“$40^1$ статья. **Татарстан Республикасы территориясендәге аеруча әһәмиятле продуктив авыл хуҗалыгы җирләре**
1. Татарстан Республикасы территориясендәге башка максатларда файдалану рөхсәт ителми торган аеруча әһәмиятле продуктив авыл хуҗалыгы җирләренә, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, түбәндәгеләр керә:

1) фәнни оешмаларның тәҗрибә-житештерү бүлекчәләренең һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының уку-тәҗрибә бүлекчәләренең авыл хуҗалыгы җирләре;

2) муниципаль район (шәһәр округы) буенча кадастр бәясе аның уртача дәрәҗәсенең 50 процентыннан һәм аннан да артыграк булган авыл хуҗалыгы җирләре;

3) селекция казанышлары сынауларын башкару, саклау һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән авыл хуҗалыгы җирләре;

4) ясалма рәвештә сугарыла торган авыл хуҗалыгы җирләре һәм стационар сугару системалары, ябык киптерү системалары булган киптерелә торган җирләр.

2. Татарстан Республикасы территориясендәге башка максатларда файдалану рөхсәт ителми торган аеруча әһәмиятле продуктив авыл хуҗалыгы җирләре исемлеге (алга таба – Исемлек) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең агросәнәгать комплексы белән идарә итү өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан төзелә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3. Исемлеккә кертелгән җир кишәрлекләре турында мәгълүмат "Интернет" челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең агросәнәгать комплексы белән идарә итү өлкәсендәге вәкаләтле органының рәсми сайтында урнаштырыла.";

5) 44 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Татарстан Республикасы милкендәге яисә муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, өч елдан алып кырык тугыз елга кадәр срокка төзелә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2014 елның 7 марты
№ 17-ТРЗ